ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
*БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ*
*БУА ШӘҺӘР СОВЕТЫ*

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
*БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН*
*БУИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ*

КАРАР
РЕШЕНИЕ

14 ноябрь 2014 ел № 1-39

Физик затлар мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибенең бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 31 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, Буа шәһәр Советы карар чыгарды:

1. Физик затлар мөлкәтенә салым салуны Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә мәҗбүри түләүгә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент нисбәтендә:
гараж һәм машина-урыны;
һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмый һәм алар шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, дача хуҗалыгы, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;
2) 0,2 процент нисбәтендә:
фатир;
бүлмә;
3) 0,3 процент нисбәтендә:
торак йортлар;
мондый объектларның проектланган билгеләнеше торак йорт булса, тәгәлләнмәгән төзелеш объектлары;
составына бер генә торак урыны (торак йорт) булса да керә торган бердәм күчемсез комплекслар;
4) 2 процент нисбәтендә:
Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;
Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларын;
салым салу объектларының һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә;
5) салым салуның башка объектларына карата 0,5 процент.

3. Үз көчен югалткан дип танырга:
- «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2009 елның 19 ноябрендәге 3-36 номерлы шәһәр Советы карарын;
- Буа шәһәр Советының «Физик затлар мөлкәтенә салымнар турында» 2009 елның 23 мартындагы 3-36 номерлы карарын.

4. Әлеге карар 2015 елның 1 гыйнварыннан һәм «Байрак» («Знамя», «Ялав») район газетасында һәм Буа муниципаль районының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында рәсми басылып чыккан көннән алып, бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башлыгы А.К. Айзетуллов